Республика Татарстан

**СОВЕТ СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ленина, д. 60, с. Старый Мензелябаш
423354
Телефон: 4-53-46

Татарстан Республикасы

**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Ленин урамы, йорт 60, Иске Минзәләбаш
авылы 423354
Телефон: 4-53-46

***ОКПО 04311866, ОГРН 1021601312237, ИНН/ КПП 1636001393/ 163601001 ОКТМО 92253472***

**РЕШЕНИЕ** **№ 17** **КАРАР**

17.09.2018 ел

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Искен Минзәләбаш авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"2019 елда үзара салым чараларын Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә кертүгә сез килешәсезме, моңа I, II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге ялгызлар, уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлар һәм вакытлы хәрби хезмәттә булучылардан тыш , җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен тоту белән дә килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге( Иске Минзәләбаш авылының Күл буе урамына вак таш җәю),
2) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерү оештыру ( Иске Минзәләбаш һәм Кужак авылларында урам яктырткычларын алыштыру; биек үскән агачларны кисү; Иске Минзәләбаш һәм Кужак авылларында урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәтмә билгеләр урнаштыру; Беларусь 320.4 маркалы трактор өчен ягулык-майлау материаллары алу; Иске Минзәләбаш һәм Кужак авыл обелискларына Бөек Ватан сугышында катнашучылар исемлеге язылган мемориаль такталар алу),
3) җирлектә яшәүчеләрнең ялын оештыру һәм мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру (Иске Минзәләбаш һәм Кужак авылларында Җиңү көнен, өлкәннәр көне, Сабантуй бәйрәмнәрен оештыру өчен бүләкләр сатып алу)

4) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту (Иске Минзәләбаш авылы зиаратындагы өйне тышлау)

ӘЙЕ ЮК"

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган мәгълүмат стендларында: Иске Минзәләбаш авылы, Ленин урамы, 58 йорт, Куҗак авылы, Совет урамы, 64 йорт һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы рәисе А.Р.Мияссарова